Березняк авыл җирлеге советы

ҚАРАР

2022 елның 24 нче ноябре № 33

«Җир салымы турында» 2013 елның 22 нче ноябрендәге 32 номерлы Березняк авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә Березняк авыл җирлеге советы карар бирде:

1. «Җир салымы турында» 2013 елның 22 нче ноябрендәге 32 номерлы Березняк авыл җирлеге Советы карарына (2014 елның 24 ноябрендәге 33 номерлы, 2015 елның 29 маендагы 24 номерлы, 2015 елның 25 ноябрендәге 10 номерлы, 2017 елнын 27 июнендәге 10 номерлы, 2018 елның 7 ноябрендәге 29 номерлы, 2018 елның 29 ноябрендәге 33 номерлы, 2018 елның декабрендәге 37 номерлы, 2019 елның 28 ноябредәге 24 номерлы, 2020 елның 28 гыйнварындагы 3 номерлы, 2020 елның 20 ноябредәге 12 номерлы Березняк авыл җирлеге Советы карарлары кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктына түбәндәге эчтәлекле «5», «6» пунктчаларын өстәргә:

«5) Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге территориясендә яшәүче, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары (алга таба – мобилизация буенча чакырылган гражданнар) һәм аларның гаиләләре әгъзалары (ире/хатыны, балигъ булмаган балалары һәм белем бирү оешмаларында көндезге уку формасы буенча укучы 23 яшькә кадәрге балалары»);

6) мобилизация буенча чакырылган гражданнарның алар белән бергә яшәүче (яшәү урыны буенча билгеләнгән тәртиптә теркәлгән) ата-аналары.»

2. «Җир салымы турында» 2013 елның 22 ноябрендәге 32 номерлы Березняк авыл җирлеге Советы карарының 3. пунктындагы «5», «6» пунктчалары нигезләмәләренең (әлеге карар редакциясендә) гамәлдә булуы 2021 елның салым чорында җир салымын исәпләүгә бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Березняк авыл җирлеге башкарма комитетына «Җир салымы турында» 2021 елның 22 ноябрендәге 32 номерлы Березняк авыл җирлеге Советы карарының 2.1 пунктның «д», «е» пунктчаларында (әлеге карар редакциясендә) күрсәтелгән гражданнар исемлеген формалаштырырга һәм салым органына тапшырырга.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында», Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Җирлек башлыгы урынбасары А.М.Фахрутдинов

ОГРН 1021607753276
ИНН 1623001847